**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның «29» декабре № 4-15

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 28.12.2021 № 17-56 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 ел 20 март № 33-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел 28 июль № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 28.12.2021 № 17-56 карарына «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» (алга таба – карар) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 28.12.2021 № 17-56 карары белән расланган) (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. преамбулада «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 ел 6 октябрь № 131-ФЗ Федераль закон нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 ел 20 март № 33-ФЗ Федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. преамбулада һәм текст буенча «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел 6 октябрь № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 ел 20 март № 33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Гражданнар җыены уздырылырга мөмкин:

1) муниципаль берәмлек территориясе составына керүче торак пунктта, әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

2) Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча муниципаль берәмлек территориясе составына керүче торак пункт территориясе өлешендә;

3) инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча муниципаль берәмлек территориясендә яисә аның территориясенең бер өлешендә.»:

1.4. Нигезләмәдә 4.1 п. «сайлау хокукына ия» сүзләреннән соң «(йә аның территориясенең бер өлеше)» сүзләрен өстәргә;

1.5. нигезләмәгә 11 нче кушымтада «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел 6 октябрь № 131-ФЗ Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 ел 20 март № 33-ФЗ Федераль законның 45 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. нигезләмәгә 14 нче кушымтада «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел 6 октябрь № 131-ФЗ Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 ел 20 март № 33-ФЗ Федераль законның 45 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында»: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Шахмай
авыл җирлеге башлыгы Н.М. Илалова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШАХМАЙКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
р 05-11944/14
СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ